КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 4 март г.Казань № 151

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре министрлыгы мәсьәләләре» 2018 ел, 11 июль, 563 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре министрлыгы мәсьәләләре» 2018 ел, 11 июль, 563 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгын үзгәртеп кору турында» 2018 ел, 22 июнь, ПУ-454 нче Указы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

2 нче пунктта «42» һәм «903,183» саннарын «47» һәм «1 027,293» саннарына алыштырырга;

3 нче пунктта «министр урынбасарын» сүзләреннән соң «, шул исәптән бер беренче урынбасарын» сүзләрен өстәргә;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре министрлыгы турындагы нигезләмәдә:

1.1 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Министрлык үз вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда эшчәнлекнең билгеләнгән өлкәсендәге товар базарларында конкуренцияне үстерү буенча максатларның һәм бурычларның өстенлекләрен тәэмин итә.»;

1.5 нче пунктта «420107» саннарын «420021» саннарына алыштырырга;

3.1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Министрлык түбәндәге төп функцияләрне гамәлгә ашыру өчен җавап бирә:

компетенция кысаларында иҗтимагый берләшмәләр эшчәнлегенә дәүләт ярдәме күрсәтүне тәэмин итү (01.16*)[1];

Татарстан Республикасында халыкка социаль-психологик ярдәм күрсәтүнең дәүләт системасын формалаштыруны һәм үстерүне билгеләнгән тәртиптә тәэмин итү (04.06.05*);

дәүләт яшьләр сәясәтен тормышка ашыру өлкәсендә идарә итү (04.07*).»;

[1]асъюлда «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары функцияләре кодификаторын раслау турында» 2006 ел, 2 май, 220 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары функцияләре кодификаторы» сүзләрен «Кодны билгеләү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары функцияләре кодификаторын раслау турында» 2006 ел, 2 май, 220 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары функцияләре кодификаторы буенча» сүзләренә алыштырырга;

3.2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2. Министрлык үз компетенциясе чикләрендә түбәндәгеләр белән үзара хезмәттәшлек итә:

Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы белән – бюджетара мөнәсәбәтләрне җайга салу (01.02.3*) функциясен гамәлгә ашырганда;

Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының норматив документлар әзерләү эшчәнлеген яраштыру (шул исәптән Татарстан Республикасы норматив хокук актлары проектларының федераль законнарга һәм Татарстан Республикасы законнарына туры килү-килмәвен тикшерүдә тоту) (02.04.01*);

республика башкарма хакимият органнарының норматив хокук актларын дәүләт теркәвенә алу (02.04.03*);

Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы белән – мәгълүматлаштыру белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.15*);

Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

фәнни һәм фәнни-техник эшчәнлек белән идарә итү (01.12*);

мәгариф белән идарә итү (04.05*);

Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

иҗтимагый берләшмәләр эшчәнлегенә дәүләт ярдәме күрсәтүне тәэмин итү (01.16*);

мәдәният (шул исәптән сәнгать, кинематография, тарихый-мәдәни мирасны саклау һәм алардан файдалану) өлкәсендә мөнәсәбәтләрне җайга салу, төрле диннәрдә булган дини берләшмәләр арасында үзара аңлашуны һәм түземлелекне ныгытуга ярдәм итү (04.03*);

Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

сәламәтлек саклау белән идарә итү (04.02*);

Татарстан Республикасында халыкның санитария-эпидемиология иминлеген тәэмин итү (04.02.13*);

Татарстан Республикасының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы белән – авыл хуҗалыгы белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (03.02*);

Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

архитектура эше белән идарә итү (01.04*);

территорияне планлаштыру буенча документлар әзерләүне тәэмин итү (01.05.02*);

объектларны төзү, капиталь ремонтлау һәм реконструкцияләү белән идарә итү (01.05.05*);

гражданнарның торакка хокукын тәэмин итү белән идарә итү (04.01.02*);

Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы белән – гражданнар оборонасы, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (02.01*);

Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы белән – муниципальара һәм шәһәр яны элемтәсендә һава, су, автомобиль транспорты белән (җиңел таксины кертеп (рөхсәтнамә бирү һәм аны яңадан рәсмиләштерү, рөхсәтнамәнең дубликатын бирү, рөхсәтнамә гамәлен вакытыннан алда туктату, Бирелгән рөхсәтнамәләр реестрын алып бару өлешендә) һәм шәһәр яны элемтәсендә тимер юл транспорты белән халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру, җиңел такси белән пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өлкәсендә төбәк дәүләт тикшерүендә тотуны гамәлгә ашыру функцияләрен гамәлгә ашырганда (03.03.02*);

Татарстан Республикасының Спорт министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

физик культура һәм спорт учреждениеләре инфраструктурасын үстерү өлкәсендә җайга салу (04.04.01*);

физкультура-савыктыру һәм массакүләм спорт чаралары (шул исәптән республика һәм муниципальара чаралар), бөтенроссия һәм халыкара спорт ярышларын һәм өйрәнү-күнегү җыеннарын оештыру белән идарә итү (04.04.02*);

Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы белән – Татарстан Республикасы милкендәге күчемсез мөлкәттән (биналар, корылмалар), транспорттан, җиһазлардан, мәдәни мирас объектларыннан файдалану белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.07.01*);

Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

хезмәт белән билгеләнгән тәртиптә идарә итү (01.13*);

иҗтимагый берләшмәләр эшчәнлегенә дәүләт ярдәме күрсәтүне тәэмин итү (01.16*);

хәйрия эшчәнлеге өлкәсендә мөнәсәбәтләрне җайга салу (01.17*);

социаль яклау белән идарә итү (04.06*);

Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

социаль-икътисадый программалар эшләү (01.01*);

инвестиция эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу (01.10*);

инновация эшчәнлеген үстерү белән идарә итү (01.11*);

Татарстан Республикасының ведомстволарга караган дәүләт мәгълүмат ресурсларын формалаштыру белән идарә итү (01.15.01.2*);

Татарстан Республикасының Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

Татарстан Республикасының тышкы икътисадый эшчәнлеге һәм ватандашлар белән мөнәсәбәтләр өлкәсендәге эшчәнлек белән идарә итү (01.03*);

сәнәгать белән идарә итү (03.01*);

эчке товар базарының аерым товарлар, хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин ителешен җайга салу (03.05*);

Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты белән – товарларга (эшләргә, хезмәт күрсәтүләргә) бәяләрне (тарифларны, өстәмәләрне, өстәмә хакларны һ.б.) билгеләнгән тәртиптә җайга салу функциясен гамәлгә ашырганда (01.09.01*);

Татарстан Республикасының Архив эшләре буенча дәүләт комитеты белән – архив эшләре белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.15.03*);

Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты белән – социаль-икътисадый мониторинг нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат ресурсларын формалаштыру белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.15.01.1*);

Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы белән – дәүләт-шәхси партнерлык һәм шәхси инвестицияләр өлкәсендә инвестиция эшчәнлеген үстерү белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.18*);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Граждан хәле актларын язу идарәсе белән – граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу эшчәнлеге белән идарә итү функциясен тормышка ашырганда (04.08*);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Балигъ булмаганнар эшләре буенча республика комиссиясе белән – балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (04.06.03*);

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы белән – иҗтимагый тәртип саклауны тәэмин итү белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (02.02*).»;

3.3 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3. Министрлык бу Нигезләмәнең 3.1 нче, 3.2 нче пунктлары нигезендә түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

1) яшьләр сәясәте үсешенә комплекслы анализ ясауны һәм аны фаразлауны тәэмин итү;

2) дәүләт һәм иҗтимагый үсеш мәнфәгатьләрендә яшьләрнең инновацион потенциалын тормышка ашыруда катнашу;

3) дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсендәге эшчәнлекне фәнни, аналитик, методик яктан тәэмин итү системасын оештыру һәм камилләштерү;

4) яшьләр мохитендә экстремизм идеяләрен таратуны, социаль, милли һәм дини түземсезлекне профилактикалауга юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыруда катнашу;

5) массакүләм мәгълүмат чаралары белән яшь гражданнарда патриотлык, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы тарихы өчен горурлык хисләрен тудыра һәм үстерә торган программалар буенча хезмәттәшлек итү;

6) яшь гаиләләргә дәүләт ярдәме күрсәтү чараларын тормышка ашыруда катнашу;

7) балаларның һәм яшьләрнең ялын, буш вакытын һәм аларны эш белән тәэмин итүне оештыруда катнашу;

8) халыкка психологик ярдәм күрсәтүнең дәүләт системасын формалаштыруны һәм үстерүне билгеләнгән тәртиптә тәэмин итү, шул исәптән:

Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары ведомствосы буйсынуындагы халыкка психологик ярдәм күрсәтүче социаль өлкә оешмалары (алга таба – социаль өлкә оешмалары) эшчәнлеген методика һәм консультация белән тәэмин итү, халыкка психологик ярдәм күрсәтү системасын яраштыру;

социаль өлкә оешмалары психологларының квалификациясен күтәрүне һәм аларны аттестацияләүне оештыру;

халыкка психологик ярдәм күрсәтү буенча, шул исәптән яшүсмерләрнең һәм яшьләрнең асоциаль һәм деструктив тәртибен профилактикалау буенча методикалар эшләүне, аларны апробацияләүне һәм социаль өлкә оешмалары эшчәнлегенә куллануышка кертүне оештыру;

социаль өлкә оешмалары тарафыннан халыкка психологик ярдәм күрсәтү буенча кулланыла торган методикаларга экспертиза үткәрүне оештыру;

гражданнарга психологик ярдәм күрсәткәндә куллану өчен тәкъдим ителә торган технологияләр буенча мәгълүматлар банкын формалаштыру һәм актуальләштерү;

9) яшьләр сәясәте өлкәсендә яшьләрнең күзәтүсезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау буенча оешмалар эшчәнлеген оештыру-методик яктан тәэмин итү һәм яраштыру;

10) дәүләт хакимияте башкарма органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар тарафыннан үткәрелә торган яшьләр белән эшләү өлешендә чаралар эшләүдә, килештерүдә һәм аларны гамәлгә ашыруда катнашу;

11) яшьләр арасында гражданлык патриотизмын формалаштыру чараларын тормышка ашыру, яшьләрне хәрби хезмәткә әзерләүдә булышлык күрсәтү;

12) балаларның һәм яшьләрнең иҗтимагый берләшмәләре проектларына һәм программаларына булышлык күрсәтү чараларын эшләүдә һәм гамәлгә ашыруда катнашу;

13) балалар һәм яшьләр өчен ял итү лагерьларында юнәлешле сменалар оештыру;

14) яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен саклауны тәэмин итү буенча чараларны тормышка ашыру һәм шартлар булдыру, яшьләр мохитендә социаль тискәре күренешләрне профилактикалау;

15) яшьләр инфраструктурасын үстерүдә катнашу, оешмаларының яшьләр белән эшләү буенча эшчәнлеген камилләштерү;

16) яшьләр сәясәте өлкәсендә оешмаларның матди-техник базасын үстерү;

17) дәүләт ярдәменнән файдаланучы яшьләр һәм балалар иҗтимагый берләшмәләренең республика реестрын формалаштыру һәм алып бару;

18) Татарстан Республикасы яшьләр сәясәте өлкәсендә дәүләт һәм муниципаль оешмаларның республика реестрын формалаштыру һәм алып бару;

19) дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсендә социаль нормаларны, нормативларны һәм стандартларны эшләүдә катнашу һәм аларның үтәлешен тикшерүдә тотуны оештыру;

20) яшьләр өчен формаль булмаган белем бирү механизмнарын һәм формаларын үстерүдә һәм гамәлгә ашыруда катнашу;

21) яшьләр сәясәте өлкәсендә статистика исәбен һәм хисаплылыкны камилләштерү буенча тәкъдимнәр эшләү;

22) яшьләр сәясәте өлкәсендә кадрлар әзерләүне, яңадан әзерләүне һәм аларның квалификациясен күтәрүне тәэмин итү;

23) һәр граждан өчен яшьләр сәясәте мәсьәләләре буенча ачык булган мәгълүмат ресурсларын булдыруда булышлык күрсәтү;

24) яшьләр сәясәте өлкәсендә халыкара һәм төбәкара хезмәттәшлекне оештыру һәм үстерү;

25) яшьләр иҗтимагый берләшмәләре эшчәнлегенә һәм аларның инициативаларына булышлык күрсәтү, Министрлык бурычларын тормышка ашырганда үзара хезмәттәшлекне оештыру;

26) дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсендә җирле үзидарә органнары белән бергәләп эшләү турында килешүләр әзерләүне һәм төзүне тәэмин итү;

27) яшьләр сәясәте өлкәсендә җирле үзидарә органнары эшчәнлеген методик яктан тәэмин итү;

28) җирле үзидарә органнары тарафыннан яшьләр сәясәте өлкәсендә үзләренә тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләре үтәлешен тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру;

29) яшьләрнең мобилизация һәм хәрби хезмәткә кадәрге әзерлеген оештыруда һәм тәэмин итүдә катнашу, Министрлыкның, эшчәнлекләре Министрлык эшчәнлегенә бәйле булган яки аның карамагы өлкәсендәге оешмаларның мобилизация әзерлеген һәм мобилизациясен оештыру һәм тәэмин итү, шулай ук бу чараларны методик яктан тәэмин итүне гамәлгә ашыру;

30) дәүләт һәм ведомство максатчан программаларын килештерү, шулай ук яшьләр сәясәтенә кагылышлы муниципаль программаларны, шул исәптән капитал салулар программаларын әзерләүдә катнашу;

31) һөнәри белем бирү оешмаларына һәм югары белем бирүче мәгариф оешмаларына кабул итүнең контроль саннарын формалаштыруда катнашу;

32) дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсендә белгечләр әзерләү программалары буенча һөнәри белем бирү оешмаларында белем алучылар өчен компетенцияләр паспортларын әзерләүдә катнашу;

33) Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарының йомгаклау коллегияләрендә кабул ителә торган карарлар өчен яшьләр сәясәте өлкәсендәге

тәкъдимнәрне, шул исәптән Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советы сессияләрендә кабул ителә торган карарлар өчен тәкъдимнәрне формалаштыруда катнашу;

34) республика һәм муниципаль дәрәҗәләрдә яшьләр эшмәкәрлеген үстерү турында тәкъдимнәр әзерләү;

35) яшьләр сәясәте өлкәсендә дәүләт һәм муниципаль оешмалар, дәүләткә карамаган оешмалар, шул исәптән яшьләр сәясәте өлкәсендә иҗтимагый оешмалар челтәрен үстерү турында тәкъдимнәр әзерләү;

36) Татарстан Республикасы социаль-икътисадый үсешенең кеше капиталы буларак яшьләр потенциалын үстерү һәм тормышка ашыру өчен шартлар булдыру турында тәкъдимнәр формалаштыру һәм аларны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертү;

37) үз эшчәнлеген Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыра торган югары белем бирүче мәгариф оешмаларының өченче буын университеты моделенә күчү стратегияләрен әзерләүдә һәм тормышка ашыруда катнашу;

38) яшьләр хәрәкәтләрен үстерү өлкәсендә дини оешмалар белән үзара хезмәттәшлек итү;

39) Татарстан Республикасы Президентының кадрлар резервында катнашучылар, Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре һәм шәһәр округлары башлыклары, һөнәри белем бирү оешмалары һәм югары белем бирүче мәгариф оешмалары өчен чыгарылыш эшләр темалары турында тәкъдимнәр әзерләү;

40) яшьләр сәясәте өлкәсендә Татарстан Республикасының ведомство буйсынуындагы дәүләт казна, бюджет һәм автоном учреждениеләрен гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыру, шул исәптән;

ведомство буйсынуындагы дәүләт учреждениеләрен төзү, үзгәртеп кору, тибын үзгәртү, бетерү турындагы карарлар проектларын әзерләү, аларның уставларын раслау һәм аларга үзгәрешләр кертү;

дәүләт учреждениесе уставында каралган төп эшчәнлек төрләре нигезендә юридик һәм физик затларга дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен формалаштыру һәм раслау;

ведомство буйсынуындагы дәүләт учреждениеләрен гамәлгә куючының башка функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыру;

ведомство буйсынуындагы дәүләт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләре сыйфаты стандартлары проектларын эшләү;

ведомство буйсынуындагы дәүләт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләре сыйфатының Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре сыйфатының билгеләнгән стандартларына туры килү-килмәвенә ел саен бәя бирүне үткәрү;

ведомство буйсынуындагы дәүләт учреждениеләре эшчәнлегенең дәүләт учреждениеләре эшчәнлеген бәяләүнең билгеләнгән критерийларына туры килү-килмәвенә бәя бирүне үткәрү;

41) үз компетенциясе чикләрендә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган Россия Федерациясендә хокук куллану мониторингын гамәлгә ашыру

методикасы нигезендә Татарстан Республикасында хокук куллану мониторингын гамәлгә ашыру;

42) урта һөнәри һәм югары белем бирү һөнәрләре һәм белгечлекләре буенча квалификацияле белгечләрне тармакта әзерләүгә ихтыяҗ фаразын формалаштыруны оештыру;

43) тармакны кадрлар белән тәэмин итү торышын өйрәнү, кеше капиталын үстерү турында тәкъдимнәр әзерләү;

44) Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан мәгариф оешмаларының студентлар отрядлары эшчәнлеген үстерүдә катнашу һәм аларның үзара хезмәттәшлеген гамәлгә ашыру;

45) һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирүче мәгариф оешмаларында белем алучыларның тәрбия эшләре буенча структуралары эшен яраштыру өчен шартлар тудыруда катнашу;

46) ireклелек (волонтерлык) өлкәсендә дәүләт сәясәтен тормышка ашыруда катнашу;

47) милли һәм төбәк социаль-икътисадый, экологик, мәдәни һәм башка үзенчәлекләрне исәпкә алып, иреклелеккә (волонтерлыкка) ярдәм күрсәтүгә юнәлдерелгән чараларны үз эченә алган Татарстан Республикасы дәүләт программаларын (ярдәмче программаларын) әзерләүдә һәм тормышка ашыруда катнашу;

48) иреклелек (волонтерлык) эшчәнлеген популярлаштыруга юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыруда катнашу;

49) иреклелек (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручылар, иреклелек (волонтерлык); оешмалары белән Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарының үзара хезмәттәшлеген яраштыру;

50) иреклелек (волонтерлык) өлкәсендә яраштыру органнарын һәм киңәшмә органнарны формалаштыру

51) дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эш башкарулар, хезмәт күрсәтүләр сатып алуларны формалаштыру;

52) планлаштырыла торган елга бюджет турындагы Татарстан Республикасы законы проектын әзерләүдә катнашу;

53) яшьләр сәясәтен тормышка ашыруга финанс чаралары белән эш итү;

54) Министрлык, шулай ук ведомство буйсынуындагы учреждениеләр эшчәнлеге буенча бухгалтерлык һәм статистика хисаплылыгын билгеләнгән вакытларда тапшыру;

55) гражданнарның Министрлык компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча тәкъдимнәрен, гаризаларын һәм шикаятьләрен законнар белән билгеләнгән вакытларда карап тикшерү;

56) яшьләр сәясәте өлкәсендә мәгълүмат һәм нәшрият эшчәнлеген гамәлгә ашыру;

57) дәүләт ихтыяҗлары һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар кайтартуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә заказлар урнаштыру өлкәсендә федераль законнар нигезендә вәкаләтле орган исеменнән эш итәргә хокуклы затның электрон санлы имзасы куелган, заказчы имзалаган контракт күчермәсен электрон мәйданчык операторына җибәрү;

58) үз компетенциясе чикләрендә экстремистлык эшчәнлегенә һәм террорчылыкка каршы торуда катнашу;

59) Министрлыкка һәм ведомство буйсынуындагы учреждениеләргә беркетелгән объектларның террорчылыктан сакланган булуына карата таләпләрнең үтәлүен оештыру һәм тәэмин итү;

60) террорчылыкка каршы тору чараларын гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары һәм җирле үзидарә органнары белән үзара хезмәттәшлекне көчәйтү максатларында укуларда катнашу;

61) үз компетенциясе нигезендә федераль башкарма хакимият органнары, аларның территориаль органнары, Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары, Россиянең һәм чит илләрнең башка органнары һәм оешмалары белән төзелгән шартнамәләрнең, килешүләрнең һәм ачык-хокукый характердагы башка актларның реестрын алып бару;

62) ел саен Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен тормышка ашыру буенча махсус дәүләт органына коррупциягә каршы сәясәт чараларын тормышка ашыру турында хисап кертү;

63) Министрлык компетенциясенә керә торган мәсьәләләр буенча гражданнар мөрәҗәгатьләрен карап тикшерү өчен Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән тәртиптә гражданнарга телдән һәм язмача хокукый консультация бирү рәвешендә түләүсез юридик ярдәм күрсәтү;

64) яшьләр сәясәте өлкәсендә оешмалар хезмәткәрләренең квалификация категорияләрен билгеләү максатларында белгечләрне һөнәри үстерүне оештыруда, аларны аттестацияләү өчен шартлар булдыруда катнашу, яшьләр сәясәте өлкәсендә стажировка мәйданчыклары булдыруда катнашу;

65) үз компетенциясе чикләрендә социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең билгеләнгән критерийларга туры килү-килмәве турында бәяләмәләр бирүне гамәлгә ашыру;

66) Министрлык компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча законнар һәм башка норматив актлар проектларын әзерләү, законнар мониторингын гамәлгә ашыру.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре министрлыгы структурасын (карарга теркәлә) яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Татарстан Республикасының Финанс министрлыгына «2019 елга һәм 2020 һәм 2021 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2018 ел, 21 ноябрь, ТРЗ-88 нче Татарстан Республикасы Законына тиешле үзгәрешләр кертү буенча тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы Премьер-министрына билгеләнгән тәртиптә кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 11 июль, 563 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 4 март, 151 нче
карары редакциясендә)

# Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре министрлыгы структурасы

